# ГАИЛӘЛӘР ЯШӘСЕН

Без бер гаилә җырга-моңга гашыйк,
Гөрләп-балкып тора өебез.
Күңелләрне күңелләргә бәйли,
Саф татарча милли көебез.

Заман белән бергә атлыйбыз без,
Уебыз бер, уртак фикерләр.
Гаилә учагының җылысында
Шундый рәхәт! Куркытмый җилләр.

Әби-бабай безнең өчен үрнәк,
Алар юлы безнең юлыбыз.
Шатлансыннар әле яши диеп,
Туган телле моңлы җырыбыз.

*Кушымта:*
Гаиләләр яшәсен, тик күзләр тимәсен,
Иң якын кешеләр яратып эндәшсен.
Тальяннар сайратып, курайлар җырлатып,
Гаиләләр яшәсен, тик күзләр тимәсен!